КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 19 май г.Казань № б-1097

1. Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче психик бозылышлы балаларның яшәү сыйфатын яхшырту, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатларында, бу боерыкка теркәлгән 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасында психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче психик бозылышлы балаларның яшәү сыйфатын яхшырту, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау буенча чаралар комплексын (алга таба – Төбәк чаралар комплексы) расларга.

2. Төбәк чаралар комплексын гамәлгә ашыру өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнарына:

тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган акча чикләрендә Төбәк чаралар комплексы чаралары үтәлешен тәэмин итәргә;

Төбәк чаралар комплексында күрсәтелгән үтәү сроклары нигезендә Төбәк чаралар комплексы үтәлеше турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мәгълүмат кертергә.

3. Төбәк чаралар комплексында күрсәтелгән федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Төбәк чаралар комплексын гамәлгә ашыруда катнашырга;

Төбәк чаралар комплексында күрсәтелгән үтәү сроклары нигезендә Төбәк чаралар комплексы үтәлеше турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мәгълүмат кертергә.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары тарафыннан бирелә торган

мәгълүматны җыюны гамәлгә ашырырга һәм ел саен, 20 гыйнварга кадәр, гомумиләштерелгән мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 19 май, б-1097 нче
боерыгы белән расланды

2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасында психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче психик бозылышлы балаларның яшәү сыйфатын яхшырту, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау буенча чаралар комплексы

| Т/с | Чараның исеме | Көтелә торган нәтиҗә | Җаваплы башкаручылар | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру | | | | |
| 1.1. | Гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре буенча территориаль программаны гамәлгә ашыруда катнашучы медицина оешмалары тарафыннан психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларга күрсәтелә торган медицина ярдәменнән файдалану мөмкинлегенә анализ ясау | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларга кирәкле медицина ярдәменнән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мәгълүмат кертү;<br>идарә карарларын кабул итү | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | 2023 елның 5 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен, 5 майга кадәр |
| 1.2. | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларга дәүләт медицина оешмаларында күрсәтелә торган | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларга дәүләт медицина оешмаларында | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | 2023 елның 5 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен, |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | медицина ярдәме күләмнәрен аналитик исәпкә алу | күрсәтелә торган медицина ярдәме күләмнәре турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына аналитик белешмә кәгазе тапшыру;<br>идарә карарларын кабул итү | | 5 майга кадәр |
| 1.3. | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларның мәҗбүри медицина иминиятен тәэмин итү һәм аларны беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларына беркетү | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларны 100% мәҗбүри медицина иминияте белән колачлау | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы; «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе; психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортлары | даими |
| | | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларны беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларына 100% беркетү | | даими |
| | | Чараны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хисап кертү | | 2023 елның 5 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен, 5 майга кадәр |
| 1.4. | Психик бозылышлары булган | Психик бозылышлары булган | Татарстан | даими |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларга ел саен диспансеризация һәм диспансер күзәтүе үткәрүне тәэмин итү | гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларны диспансеризацияләр һәм диспансер күзәтүе белән 100% колачлау | Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы; психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортлары | |
| | | Чараны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хисап кертү | | 2023 елның 5 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен, 5 майга кадәр |
| 1.5. | Социаль хезмәтләр күрсәтү җыелмасы кысаларында психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларны дару белән тулысынча һәм үз вакытында тәэмин итүне контрольдә тотуны тәэмин итү | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән һәр балалар интернат йортында ел саен кимендә бер тикшерү үткәрү | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | ел саен |
| | | Чараны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хисап кертү | | 2023 елның 5 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен, 5 майга кадәр |
| 1.6. | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларына күзәтү өчен урнаштырылган инвалид | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче, тиешле медицина | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль | даими |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | балаларга карата дару препаратлары, медицина әйберләре, шулай ук социаль хезмәтләр җыелмасы кысаларында дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктларын бирү турындагы гаризаны үз вакытында тапшыруны тәэмин итү | тәкъдимнәре булган балаларның социаль хезмәтләр күрсәтү җыелмасы кысаларында дару препаратлары, медицина әйберләре, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары белән тәэмин ителеше | яклау министрлыгы; психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортлары | |
| | | Чараны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хисап кертү | | 2023 елның 5 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен, 5 майга кадәр |
| 1.7. | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларны профилактика прививкаларының илкүләм календаре һәм эпидемия күрсәткечләре буенча прививкалар календаре кысаларында үз вакытында вакцинацияләүне тәэмин итү | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларны 100% вакцинация белән колачлау | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы; психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортлары | ел саен |
| | | Чараны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хисап кертү | | 2023 елның 5 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен, 5 майга кадәр |
| 1.8. | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау | даими |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | яшәүче балаларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру | яшәүче балаларны 100% психиатрия ярдәме белән тәэмин итү | министрлыгы; психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортлары | |
| | | Чараны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хисап кертү | | квартал саен, хисап аеннан соң килә торган айның 5енә кадәр |
| 1.10. | 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасында психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче психик бозылышлы балаларның яшәү сыйфатын яхшырту, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау буенча бу чаралар комплексының (алга таба – Төбәк чаралар комплексы) 1.1 – 1.9 пунктларында каралган чаралар турында аналитик белешмә кәгазен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына (алга таба – Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җибәрү | Медицина ярдәме күрсәтү өлешендә психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларның яшәү сыйфатын яхшырту, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау максатларында чараларның нәтиҗәлелеген бәяләүне үз эченә алган аналитик белешмә кәгазе | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | 2023 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен, 1 майга кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 1.11. | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче инвалид балаларның дару чаралары белән тәэмин ителешен бәяләү максатларында федераль бюджетның һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән дарулар, медицина әйберләре һәм дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары белән тәэмин итүгә хокуклы Инвалидлар федераль реестрындагы һәм Гражданнар федераль регистрындагы мәгълүматларны чагыштырып тикшерү | Чагыштырып тикшерү нәтиҗәләре турындагы белешмә кәгазе | Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге (килешү буенча); Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 5енә кадәр |
| 2. Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче инвалид балалар реабилитацияләүне яки абилитацияләүне оештыру | | | | |
| 2.1. | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларны медицина-социаль экспертизага үз вакытында җибәрүне тәэмин итү | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларга 100% үз вакытында медицина-социаль экспертиза үткәрү | «Татарстан Республикасы буенча Баш медик-социаль экспертиза бюросы» федераль казна учреждениесе (килешү буенча); Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы; | даими |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы; психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат-йортлары | |
| | | Татарстан Республикасының стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында, шул исәптән психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче гражданнарга билгеләнгән реабилитация чаралары турында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Россия Хезмәт министрлыгына) хисап | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы; «Татарстан Республикасы буенча Баш медик-социаль экспертиза бюросы» федераль казна учреждениесе (килешү буенча) | квартал саен, хисап аеннан соң килә торган айның 15енә кадәр |
| 2.2. | Тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү өлешендә инвалид баланы реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын гамәлгә ашыруны тәэмин итү | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче, инвалид баланы реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында тиешле | Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге (килешү буенча) | даими |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | тәкъдимнәре булган балаларның 100% тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин ителеше | | |
| | | Чараны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хисап кертү | | квартал саен, хисап аеннан соң килә торган айның 5енә кадәр |
| 2.3. | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче һәм туклануы җитәрлек булмаган балаларны дәвалау туклануы белән тәэмин итү | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче, тиешле медицина тәкъдимнәре булган балаларны 100% дәвалау туклануы белән колачлау | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы; психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортлары | даими |
| | | Чараны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хисап кертү | | квартал саен, хисап аеннан соң килә торган айның 5енә кадәр |
| 3. Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларга социаль хезмәт күрсәтүләрне, шул исәптән көндезге эш белән мәшгульлекне оештыру | | | | |
| 3.1. | Балаларны көндезге эш белән мәшгульлеген тәэмин итүне оештыру өчен психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларын кадрлар белән тәэмин итүгә | Булган проблемаларны күрсәтеп, мониторинг үткәрү йомгаклары буенча аналитик белешмә кәгазе; идарә карарларын кабул итү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | ел саен, 5 октябрьгә кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | мониторинг үткәрү | | | |
| 3.2. | Россия Хезмәт министрлыгының методик тәкъдимнамәләре нигезендә психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларның шәхси делоларын алып бару тәртибе турында оешманың локаль актын эшләү | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортының локаль актлары | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 елның 1 июненә кадәр |
| 3.3. | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортлары биналарының (бүлмәләренең) матди-техник базасын ныгыту, кирәкле җиһазлар белән, шул исәптән балаларның көндезге эш белән мәшгульлеген тәэмин итү өчен өстәмә җиһазлау (яңадан җиһазландыру) | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында көндезге эш белән мәшгульлеген тәэмин итүне оештыру өчен төзекләндерелгән бүлмәләр булу<br>Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларының, шул исәптән балаларның көндезге эш белән мәшгульлеген тәэмин итү өчен, җиһазлар белән тәэмин ителеше | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы; психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортлары | ел саен |
| 4. Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларга белем бирүне оештыру | | | | |
| 4.1. | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында | Мәгариф өлкәсендә законнарны регламентлаштыра торган нормативларны исәпкә алып, | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 2023 елның 5 октябренә кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | яшәүче балаларга гомуми белем бирүне, өстәмә белем бирүне, һөнәри белем бирүне һәм психологик-педагогик булышлык күрсәтеп торуны кадрлар белән тәэмин итү (актуаль һәм ихтыяҗи) мониторингы | психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларда яшәүче балаларга белем бирүне һәм психологик-педагогик булышлык күрсәтеп торуны тәэмин итү турында аналитик белешмә кәгазен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җибәрергә;<br>тиешле идарә карарларын кабул итү | | (арадаш), алга таба – ел саен, 1 июньгә кадәр |
| 4.2. | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларда яшәүче балаларның белем алу мөмкинлеген һәм сыйфатын тәэмин итү мәсьәләләре буенча оешмаларның педагогик хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларда яшәүче балаларның белем алу мөмкинлеген һәм сыйфатын тәэмин итү мәсьәләләре буенча буенча квалификация күтәрү программалары буенча укытуны колачлау (арта бара торган йомгак белән):<br>2023 ел – педагогик хезмәткәрләрнең 25 %ы;<br>2024 ел – педагогик хезмәткәрләрнең 75 %ы;<br>2025 ел – педагогик хезмәткәрләрнең 100%ы. | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | ел саен |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Чараны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хисап кертү | | квартал саен, хисап аеннан соң килә торган айның 5енә кадәр |
| 4.3. | Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (алга таба – Россия Мәгариф министрлыгы) тарафыннан эшләнгән үрнәк модуль программаларын исәпкә алып, психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларга гомуми белем бирү, өстәмә белем бирү, һөнәри белем бирү һәм психологик-педагогик булышлык күрсәтеп тору өлкәсендә һөнәри программаларны тормышка ашыру | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларны мәктәпкәчә һәм мәктәптә белем бирү программалары буенча укыту белән 100% колачлау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | ел саен |
| | | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларның кимендә 40 процентын өстәмә белем бирү программалары буенча укыту белән 100% колачлау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы; психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортлары | |
| | | Чараны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хисап кертү | | квартал саен, хисап аеннан соң килә торган айның 5енә кадәр |
| 4.4. | Россия Мәгариф министрлыгының методик әсбапларында тәкъдим ителгән белем бирүнең дифференциацияләнгән рәвешләрен исәпкә алып, психик бозылышлары | Белем бирүнең дифференциацияләнгән рәвешләрен исәпкә алып, психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 2023 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларга гомуми белем бирүне, өстәмә белем бирүне, һөнәри белем бирүне һәм психологик-педагогик булышлык күрсәтеп торуны оештыруның дифференциацияләнгән рәвешләрен камилләштерү | интернат йортларында яшәүче балаларга гомуми белем бирүне, өстәмә белем бирүне, һөнәри белем бирүне һәм психологик-педагогик булышлык күрсәтеп торуны оештыру мониторингы нәтиҗәләре буенча аналитик белешмә кәгазен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җибәрү | | саен, 1 майга кадәр |
| 4.5. | Төбәк чаралар комплексының 4.1 – 4.4 пунктларында каралган чаралар турындагы аналитик белешмә кәгазен Россия Мәгариф министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җибәрү | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларга белем бирү турында аналитик белешмә кәгазе идарә карарларын кабул итү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 2023 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен, 1 майга кадәр |
| 5. Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында күзәтүдә астында торучы ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокукларын яклауны тәэмин итү | | | | |
| 5.1. | Опека һәм попечительлек органнары тарафыннан психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат-йортларында яшәүче ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның мөлкәти хокукларын | Опека һәм попечительлек органнары тарафыннан психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 2023 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен, 1 майга кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | (алиментка хокук, пенсия белән тәэмин итү, торак урыннарның сакланышы, опека органнары тарафыннан балаларның акчаларын тотуга һәм мөлкәте белән алыш-биреш итүгә рөхсәт бирү, опекун (попечитель) хисапларын тапшыру, балаларның мөлкәти хокукларын яклау мәсьәләләре буенча дәгъвалар бирү) яклауны тәэмин итүне тикшерүләрне гамәлгә ашыру мониторингы | балаларның мөлкәти хокукларын яклауны тәэмин итүне тикшерүләрне гамәлгә ашыру турында аналитик белешмә кәгазе (опекунның (попечительнең) кабул ителгән һәм расланган хисаплары санын, законлы вәкил тарафыннан да, опека органнары тарафыннан да бирелгән балаларның мөлкәти хокукларын яклау мәсьәләләре буенча дәгъвалар санын, шулардан канәгатьләндерелгәнен күрсәтеп) | | |
| | | Мониторинг йомгаклары буенча аналитик белешмә кәазен теркәп, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының, шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре адресларына хатлар | | 2023 елның 1 октябренә кадәр, алга таба – ел саен, 1 майга кадәр |
| 6. Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында яшәүче балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру, саклау һәм яклау механизмнары эшләве нәтиҗәлелеген күтәрү эшчәнлеген координацияләү | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 6.2. | Төбәк чаралар комплексы чараларын гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм контрольдә тоту, Россия Хезмәт министрлыгының статистика җыю буенча рәсми сайтында мониторинг күрсәткечләренең үтәлеше турында мәгълүматлар кертү | Төбәк чаралар комплексы чараларын гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм контрольдә тоту йомгаклары булган аналитик белешмә кәгазе;<br>идарә карарларын кабул итү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 елның 1 сентябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен, 1 мартка кадәр |
| 6.3. | Төбәк чаралар комплексын гамәлгә ашыру турында бердәм доклад әзерләү һәм аны Россия Хезмәт министрлыгына, Россия Сәламәтлек саклау министрлыгына, Россия Мәгариф министрлыгына һәм Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә җибәрү | Төбәк чаралар комплексын гамәлгә ашыру турында доклад | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 2023 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен, 1 майга кадәр |